Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Барыш авыл җирлеге Советы
КАРАРы

«31» май 2021 ел № 25

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 апрелендә кабул ителгән 20 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында " карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советы

КАРАР:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 апрелендәге 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр " сүзләрен өстәргә;

2) 29 статьяның 4 пунктына «(булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга .pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга (kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Барыш авыл җирлеге башлыгы
Кама Тамагы муниципаль районы,
Иске Барыш авыл җирлеге Советы Рәисе
Кама Тамагы муниципаль районы
муниципаль район башлыгы И. Р. Җиһаншин